МИНИСТЕРСТВО СТРОИТЕЛЬСТВА, АРХИТЕКТУРЫ И ЖИЛИЩНО-КОММУНАЛЬНОГО ХОЗЯЙСТВА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ТӨЗЕЛЕШ, АРХИТЕКТУРА ҺӘМ ТОРАК-КОММУНАЛЬ ХУҖАЛЫГЫ МИНИСТРЛЫГЫ

№ 180/о

ПРИКАЗ БОЕРЫК

«17» 10 2018

Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының 2017 елның 11 октябрендәге 181/о номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының Татарстан Республикасының ике һәм аннан күбрәк муниципаль берәмлеге (шәһәр округы, муниципаль районы) территориясендәге су объектында ясалма җир кишәрлеге булдырылган очракта, ясалма булдырылган җир кишәрлеген эксплуатациягә кертүгә рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының «Татарстан Республикасының ике һәм аннан күбрәк муниципаль берәмлеге (шәһәр округы, муниципаль районы) территориясендәге су объектында ясалма җир кишәрлеге булдырылган очракта, ясалма булдырылган җир кишәрлеген эксплуатациягә кертүгә рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2017 елның 11 октябрендәге 181/о номерлы боерыгы (Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының 2018 елның 28 маендагы 97/о номерлы боерыгы нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) белән расланган Татарстан Республикасының ике һәм аннан күбрәк муниципаль берәмлеге (шәһәр округы, муниципаль районы) территориясендәге су объектында ясалма җир кишәрлеге булдырылган очракта, ясалма булдырылган җир

кишәрлегән эксплуатациягә кертүгә рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына кертелә торган, кушымтада бирелгән үзгәрешләрне расларга.

2. Юридик бүлек башлыгы Э.Ю.Латыйповага дәүләт теркәвенә алу өчен шушы боерыкның Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына җибәрелүен тәэмин итәргә.

3. Массакүләм мәгълүмат чаралары белән хезмәттәшлек секторы җитәкчесе Г.С.Миңнехановага әлеге боерыкның «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының рәсми сайтында урнаштырылуын тәэмин итәргә.

Министр И.Ә.Фәйзуллин

ОТДЕЛ ОРГАНИЗАЦИОННО-ПРОТОКОЛЬНОЙ РАБОТЫ, КОНТРОЛЯ И ДЕЛОПРОИЗВОДСТВА

Татарстан Республикасы
Төзелеш, архитектура һәм
торак-коммуналь хуҗалыгы
министрлыгының 2018 елның
17 октябрендәге 180/о номерлы
боерыгы белән расланды

Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының «Татарстан Республикасының ике һәм аннан күбрәк муниципаль берәмлеге (шәһәр округы, муниципаль районы) территориясендәге су объектында ясалма җир кишәрлеге булдырылган очракта, ясалма булдырылган җир кишәрлеген эксплуатациягә кертүгә рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2017 елның 11 октябрендәге 181/о номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасының ике һәм аннан күбрәк муниципаль берәмлеге (шәһәр округы, муниципаль районы) территориясендәге су объектында ясалма җир кишәрлеге булдырылган очракта, ясалма булдырылган җир кишәрлеген эксплуатациягә кертүгә рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына кертелә торган үзгәрешләр

Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының «Татарстан Республикасының ике һәм аннан күбрәк муниципаль берәмлеге (шәһәр округы, муниципаль районы) территориясендәге су объектында ясалма җир кишәрлеге булдырылган очракта, ясалма булдырылган җир кишәрлеген эксплуатациягә кертүгә рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2017 елның 11 октябрендәге 181/о номерлы боерыгы (Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының 2018 елның 28 маендагы 97/о номерлы боерыгы нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) белән расланган Татарстан Республикасының ике һәм аннан күбрәк муниципаль берәмлеге (шәһәр округы, муниципаль районы) территориясендәге су объектында ясалма җир кишәрлеге булдырылган очракта, ясалма булдырылган җир кишәрлеген эксплуатациягә кертүгә рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентында:

1.3.5 пунктчаның икенче абзацында «белешмәләрне үз эченә ала» сүзләреннән алда «Татарстан Республикасы дәүләт телләрендәге» сүзләрен өстәргә;

1.5 пунктның өченче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче күпфункцияле үзәкнең читтән торып эшләү урыны – дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче күпфункцияле үзәкнең «Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче күпфункцияле үзәкләр эшчәнлеген оештыру кагыйдәләрен раслау турында» 2012 елның 22 декабрендәге 1376 номерлы Россия Федерациясе

Хөкүмәте карары белән расланган Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче күпфункцияле үзәкләр эшчәнлеген оештыру кагыйдәләренең 34 пункты нигезендә Татарстан Республикасының шәһәр яки муниципаль район (шәһәр округы) авыл җирлегендә булдырылган территориаль аерымланган структур бүлекчәсе (офисы).»;

2.6 пунктта «Стандартка карата таләпләр эчтәлеге» графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Әлеге Регламентның 2.5 пунктындагы җиденче абзацта күрсәтелгән документлар (аларның күчермәләре яисә аларда булган белешмәләр) түбәндәгеләрдән соратыла:

Министрлыкта (ясалма рәвештә җир кишәрлеге булдыру эшләрен уздыруга рөхсәт яисә, 246-ФЗ номерлы федераль законның 16 статьясында күрсәтелгән очракта, капиталь төзелеш объектын төзүгә рөхсәт);

Татарстан Республикасы Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясеннән (дәүләт төзелеш күзәтчелеге органының ясалма рәвештә булдырылган җир кишәрлегенең техник регламентлар һәм проект документациясе таләпләренә җавап бирүе турында бәяләмәсе, дәүләт экология күзәтчелеге бәяләмәсе).

Мөрәҗәгать итүче тарафыннан югарыда күрсәтелгән документларның тапшырылмавы дәүләт хезмәтен күрсәтү буенча документларны кабул итүдән баш тартуга нигез була алмый.

Мөрәҗәгать итүчедән түбәндәгеләрне таләп итү тыела:

югарыда саналган, дәүләт хезмәтләрен һәм муниципаль хезмәтләрне күрсәтүче органнар, бүтән дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары яисә дәүләт хезмәтләрен һәм муниципаль хезмәтләрне күрсәтүдә катнашучы дәүләт органнарының яки җирле үзидарә органнарының ведомство буйсынуында торган оешмалар карамагында булган документларны, 210-ФЗ номерлы федераль законның 7 статьясының 6 өлешендә каралган документлардан тыш;

дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән яки дәүләт хезмәтен күрсәтүдән беренче мәртәбә баш тартканда булмавы һәм (яки) дөрес булмавы күрсәтелмәгән документлар һәм мәгълүматлар тапшыруны, түбәндәге очраклардан тыш:

дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза беренче мәртәбә тапшырылганнан соң дәүләт хезмәтен күрсәтүгә кагылышлы норматив хокукый актларның таләпләре үзгәргәндә;

дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән яки дәүләт хезмәтен күрсәтүдән беренче мәртәбә баш тартудан соң дәүләт хезмәтен күрсәтү турында мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырылган һәм элегрәк тапшырылган документлар җыелмасына кертелмәгән гаризада һәм документларда хаталар булганда;

дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән яки дәүләт хезмәтен күрсәтүдән беренче мәртәбә баш тартудан соң документларның гамәлдә булу срогы беткәндә яисә мәгълүматлар үзгәргәндә;

дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән яки дәүләт хезмәтен күрсәтүдән беренче мәртәбә баш тартканда дәүләт хезмәте күрсәтүче органдагы вазыйфаи затның, дәүләт хезмәткәренең ялгыш яки хокукка

каршы килә торган гамәлен (гамәл кылмавын) документаль раслаучы факт (билгеләр) ачыкланганда, бу хакта мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәтен күрсәтүче орган җитәкчесенең имзасы белән язмача рәвештә хәбәр ителә, шулай ук китерелгән уңайсызлыклар өчен гафу үтенелә»;

3.3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.3. Шушы Регламентның 2.5 пункты нигезендә документлар пакетын теркәп, рөхсәт бирү турында гаризаны кабул итү һәм теркәү, тапшырылган документларның тулы булу-булмавын тикшерү.

Мөрәҗәгать итүче дәүләт хезмәтен үткәрү турында гаризаны шәхсән үзе, ышанычлы заты аша, электрон рәвештә тапшыра яисә почта буенча (кулга тапшырылу турындагы тамга һәм теркәлгәннәрнең исемлеге белән) җибәрә һәм шушы Регламентның 2.5 пункты нигезендә документлар тапшыра.

1 нче кушымтада расланган рәвештә дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза тапшырылган көнне Министрлыкның документларны кабул итү белән шөгыльләнүче Бүлек белгечләре гаризаны Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең «Электрон Хөкүмәт» бердәм ведомствоара электрон документ әйләнеше системасында терки, мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырылган документларның тулы булу-булмавын әлеге Регламентның 2.5 пунктында билгеләнгән документлар исемлегенә туры китереп тикшерә.

Документлар җыелмасы федераль законнарда билгеләнгән таләпләргә (шушы Регламентның 2.5 пункты) җавап биргән очракта, гариза алга таба эш итү өчен кабул ителә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар әлеге Регламентның 2.5 п. нигезендә документлар белән берлектә ясалма рәвештә булдырылган җир кишәрлеген эксплуатациягә кертүгә рөхсәт бирү турында гариза килгән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: ясалма булдырылган җир кишәрлеген эксплуатациягә кертүгә рөхсәт бирү турында гаризаны теркәү.»;

3.4.1 пунктның дүртенче абзацында «1 эш көне эчендә» сүзләрен «бер көн эчендә» сүзләренә алмаштырырга;

3.5 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.5. Дәүләт хезмәте нәтиҗәсен әзерләү.»;

3.5.1 пунктта:

бишенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Рөхсәт бирүдән баш тарту турында хәбәрләмә белән берлектә мөрәҗәгать итүчегә (аның вәкаләтле вәкиленә) аның тарафыннан кәгазьдә тапшырылган барлык документлары кайтарыла. Электрон рәвештә тапшырылган документлар гариза тапшырылган көннән соң кимендә 3 ай дәвамында сакланырга тиеш.»;

алтынчы абзацта «1 эш көне эчендә» сүзләрен «ике көн эчендә» сүзләренә алмаштырырга;

3.5.2 пунктта:

беренче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.5.2. Бүлек белгечләре тапшырылган документлар әлеге Регламентның 2.5 пункты таләпләренә җавап бирмәгән очракта:»;

бишенче абзацта «1 эш көне эчендә» сүзләрен «ике көн эчендә» сүзләренә

алмаштырырга;

5.2 пунктта:

3 пунктчада «каралмаган документларны тапшыруны» сүзләрен «тапшырылуы яки гамәлгә ашырылуы каралмаган документларны яки мәгълүматны тапшыруны яисә гамәлләрне башкаруны» сүзләренә алмаштырырга;

түбәндәге эчтәлекле 10 пунктча өстәргә:

«10) дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән яки дәүләт хезмәте күрсәтүдән беренче мәртәбә баш тартканда, 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы федераль законның 7 статьясының 1 өлешендәге 4 пунктында каралганнардан тыш, булмавы һәм (яки) дөрес булмавы турында күрсәтелмәгән документларны яки мәгълүматны мөрәҗәгать итүчедән таләп иткәндә.»;

5.7 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.7. Шикаятьне карау нәтиҗәләре буенча түбәндәге карарларның берсе кабул ителә:

1) шикаять канәгатьләндерелә, шул исәптән кабул ителгән карарны гамәлдән чыгару, дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда җибәрелгән хаталарны һәм ялгышларны төзәтү, мөрәҗәгать итүчегә Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында алуы каралмаган түләүләрне кайтарып бирү рәвешендә;

2) шикаятьне канәгатьләндерүдән баш тартыла.

Шушы пунктта күрсәтелгән карарны кабул иткән көннән соң бер көн узганчы мөрәҗәгать итүчегә язмача яисә аның ихтыяры буенча электрон рәвештә шикаятьне карап тикшерү нәтиҗәләре турында нигезләнгән хат җибәрелә.

Шикаять канәгатьләндерелергә тиеш дип танылган очракта, җавапта мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәтен күрсәткәндә ачыкланган җитешсезлекләрне кичекмәстән юк итү максатларында дәүләт хезмәтен күрсәтүче орган тарафыннан гамәлгә ашырыла торган гамәлләр турында мәгълүмат бирелә, шулай ук китерелгән уңайсызлыклар өчен гафу үтенелә һәм дәүләт хезмәтен алу максатларында алга таба мөрәҗәгать итүче эшләргә тиешле гамәлләр турында мәгълүмат күрсәтелә.

Шикаять канәгатьләндерергә тиешле түгел дип танылган очракта, мөрәҗәгать итүчегә җавапта кабул ителгән карарның сәбәпләре турында нигезле аңлатмалар, шулай ук кабул ителгән карарга шикаять белдерү тәртибе турында мәгълүмат күрсәтелә.»;

түбәндәге эчтәлекле 5.8 пунктны өстәргә:

«5.8. Шикаятьне карау барышында яисә нәтиҗәсендә административ хокук бозу яки җинаять кылу билгеләре ачыкланган очракта, шикаятьләрне карау вәкаләте бирелгән вазыйфаи зат булган материалларны прокуратура органнарына кичекмәстән җибәрә.».